**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью $11^2$ Закона Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в сфере охраны здоровья граждан в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 марта 2021 года

**Статья 1**

Внести в статью $11^2$ Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2012 года № 87-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере охраны здоровья граждан в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 12 (I часть); 2013, № 12 (I часть); 2014, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 3, № 10 (I часть); 2016, № 3, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2017, № 52 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 83 (часть I); 2019, № 28 (часть I); 2020, № 26 (часть I), № 87 (часть I) изменение, изложив ее в следующей редакции:

«Статья $11^2$. **Организация и осуществление мероприятий по оказанию помощи лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения**

1. Лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения, оказывается помощь в создаваемых в этих целях специализированных организациях.
2. Специализированные организации для оказания помощи лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения (далее – специализированные организации), создаются в форме государственных, муниципальных учреждений.
3. Помощь лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения, оказывается за счет средств бюджета Республики Татарстан в специализированных организациях, созданных в следующих муниципальных образованиях Республики Татарстан: город Казань,

«город Набережные Челны», Азнакаевский муниципальный район, Альметьевский муниципальный район, Бугульминский муниципальный район, Елабужский муниципальный район, Заинский муниципальный район, Зеленодольский муниципальный район, Лениногорский муниципальный район, Нижнекамский муниципальный район, Чистопольский муниципальный район.

4. Полномочия по организации и осуществлению мероприятий по оказанию помощи лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения, включая создание специализированных организаций, могут быть переданы для осуществления органам местного самоуправления в порядке, установленном федеральным законодательством.

5. Органы местного самоуправления вправе осуществлять мероприятия по оказанию помощи лицам, находящимся в состоянии алкогольного, наркотического или иного токсического опьянения, за счет доходов местных бюджетов, за исключением межбюджетных трансфертов, предоставленных из бюджетов бюджетной системы Российской Федерации, и поступлений налоговых доходов по дополнительным нормативам отчислений.

6. Деятельность специализированных организаций организуется в соответствии с правилами, утвержденными уполномоченными федеральными органами исполнительной власти.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
08 апреля 2021 года
№ 22-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11$^2$ статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11$^2$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«11$^2$ статья. **Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру**

1. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга әлеге максатларда булдырыла торган махсуслаштырылган оешмаларда ярдәм күрсәтелә.
2. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмалар (алга таба – махсуслаштырылган оешмалар) дәүләт, муниципаль учреждениеләр рәвешендә төзелә.
3. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә оештырылган махсуслаштырылган оешмаларда күрсәтелә: Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль

районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Чистай муниципаль районы.

4. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру вәкаләтләре, махсуслаштырылган оешмалар төзүне дә кертеп, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына башкару өчен тапшырылырга мөмкин.

5. Җирле үзидарә органнары алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын җирле бюджетлар керемнәре хисабына гамәлгә ашырырга хокуклы, моңа Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлар һәм өстәмә түләү нормативлары буенча салым керемнәре керми.

6. Махсуслаштырылган оешмаларның эшчәнлеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә оештырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 08 апрель
№ 22-ТРЗ